| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ТЕЛӘЧЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** — с. Тюлячи — **БОЕРЫК**

«27» мая 2024г. — № 109

2024 елда балаларның мәктәп яны лагерьларына көндез йөрүләре өчен ташламалар бирү турында

Теләче муниципаль районы МКУ «Башкарма комитеты Мәгариф бүлеге»нең 2024 елның 7 маендагы 196 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары белән расланган Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында Нигезләмә нигезендә,

1. Балаларның мәктәп яны лагерьларына көндез йөрүләре өчен түләүдән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар арасыннан булган махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең һәм затларның, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренең гаиләләрен (гаилә әгъзаларын), шулай ук шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләре гаиләләрен (гаилә әгъзаларына) азат итәргә.

2. Мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә гамәлдәге законнар нигезендә ташламалар бирүне тәэмин итәргә.

3. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның балаларына көндезге лагерь өчен ата-аналар түләве өлешендә район бюджеты исәбеннән финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче — И.Х. Хәмидуллин